ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

28.04.2020　　　　　　　　№ 244

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 декабрендәге 1021 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 1 мартындагы 35-ФЗ номерлы «Ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциясен раслау турында» 2018 елның 10 декабрендәге 1021 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

««Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»ның 8 кушымтасындагы 2.5 пунктының 3 пунктчасында; 3нче пунктчада, «Социаль наем шартнамәсе буенча гражданга торак урыны, муниципаль торак фонды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»нда 5 кушымтаның 2.5 пунктының 5 пунктчасының 4 абзацында «уллыкка (кызлыкка) алу турында карар» дигән сүзтезмәне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　Л.Н. Маняпов